ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасына 2025 елда түбәндәгеләрне үткәрүне йөкләргә:

2022 – 2024 елларда һәм 2025 елның узган чорында авыл халкына беренчел медицина-санитария ярдәме оештыруга (күрсәтүгә) бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларыннан нәтиҗәле файдалану аудитын;

2022 – 2024 елларда һәм 2025 елның узган чорында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеген тәэмин итүгә, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан нәтиҗәле файдалану аудитын.

2. Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2025 елның IV кварталында тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе                                        Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 221-VII ДС